**МБГБУ- Иске Җөри урта гомумбелем бирү мәктәбе башлангыч профсоюз комитетының 2023 нче елга отчеты.**

Иске Җөри урта мәктәбенең башлангыч профсоюз оешмасында Иске Җөри урта мәктәбеннән 13 укытучы һәм 7 ярдәмче хезмәткәр, башлангыч мәктәпләрдән 5 укытучы һәм 1 ярдәмче хезмәткәр, Иске Җөри балалар бакчасыннан 10 – барысы 36 хезмәткәр әгъза булып торалар. Шулай ук безнең мәктәплрдән эшләп ялга чыккан 31, балалар бакчасыннан -4 – барысы 35 пенсионерыбыз бар. Шуларның бкрсе профсоюзда калды. Безнең оешма профсоюз уставы белән башлангыч профсоюз оешмасы турында төзелгән положение һәм еллык план нигезендә эш алып бара. Профсоюз оешмасы белән админстрация арасында төзелгән килешүдәге барлык пунктларның үтәлү үтәлмәве профком утырышларында яисә директор алды киңәшмәләрендә тикшерелә. Без – профсоюз оешмасы мәктәп дирекциясе белән килешеп, аңлашып эшлибез. Безнең оешманың төп бурычы булып түбәндәгеләр тора:

- Администрация каршында Профсоюз членнарының мәнфәгатьләрен, социаль-икътисади хокукларын яклау;
- Профсоюз членнарына социаль һәм хокукый яклау буенча киңәшләр бирү;
- Профсоюз членнарының буш вакытларын файдалы итеп үткәрергә булышу.

Конституциядә каралганча, барлык сау-сәламәт кеше хезмәткә хокуклы. Тырышып хезмәт итү һәм хезмәт диципплинасын үтәү һәркемнең төп бурычы. Хезмәт дисциплинасы ул- эчке тәртип кагыйдәләрен үтәү генә түгел, ә үз профессияңә аңлы рәвештә иҗади якын килеп, югары нәтиҗәләргә ирешү, эш вакытын дөрес итеп файдалану. Һәр яна уку елы башында , 1нче профсоюз җыелышында эчке тәртип кагыйдәләре тикшерелә һәм кабул ителә. Эчке тәртип кагыйдәләре хезмәткә аңлы караш булдыруны, хезмәт дисциплинасын ныгытуны, эш сәгатен дөрес файдалануны, югары нәтиҗәлелеккә ирешүне максат итеп ала. Хезмәткәрләрне эшкә алу хезмәткәрнең шәхси гаризасы һәм приказ нигезендә башкарыла , тиешле документлар туплана. Хезмәт килешүе төзелә. Эшкә килгән һәрбер хезмәткәр

мәктәп уставы, эчке тәртип кагыйдәләре, эш шартлары, хезмәт хакы, хокук һәм бурычлары белән таныштырыла.

Мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында 6 көнлек эш атнасы. Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты дәресләр расписаниесе һәм төп вазифаларыннан чыгып билгеләнә. Мәктәптәге укытучылар барысы да 18 сәгатьтән ким булмаган дәрес саны белән тәэмин ителгәннәр. Хезмәт күрсәтүче эшчеләрнең эш вакыты хезмәт кодексы нигезендә атнасына 36 сәгать тәшкил итә. Бәйрәм алларыннан эш көннәре 1 сәгатькә кыскартыла. Коллективтагы барлык кешеләр дә елга бер тапкыр бушлай медицина тикшерүе үтәләр. Мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында эшләүче 16 яше тулмаган балалары булган хатын-кызларга айга 1 көн, инвалид баласы булганнарга 4 көн бушлай түләүле ял бирелеп килә. Бу, нигездә, якындагы каникул вакытында башкарыла.

Уку елы дәверендә 2-3 хезмәткәргә матди ярдәм күрсәтәбез. Коллективыбыз бик дус, тату. Шатлыкларны бүлешеп, кайгыларны уртаклашып яшибез. Шулай ук түләүле яллар хезмәткәр үзе өйләнгән яки кияүгә чыккан очракта 3 көн, баласы туена 1көн, яңа йортка күчкәндә 2 көн, якыны үлгән очракта 3 көн, улын армиягә озатучыга 2 көн, баласын беренче тапкыр 1 сыйныфка озатучыга һәм 11 сыйныфта соңгы звонок бәйрәмнәренә бару өчен 1көн бирелеп килә.

Эш белән беррәттән үзебезнең ялыбызны да күңелле итеп оештырабыз. Ел саен Казан шәһәренә экскурсиягә барабыз. Укытучылар көне, Яңа ел, 8 март, 23 февраль бәйрәмнәрен матур итеп оештырабыз. Культуралы ял итүдә ветераннарыбызны да онытмыйбыз. Белем бәйрәме, Өлкәннәр көне, Укытучылар көне, Соңгы кыңгырау бәйрәмнәренә чакырабыз. Истәлекле бүләкләр тапшырабыз, чәй табыны әзерлибез, өлкәннәр көненә күчтәнәчләр җибәрәбез, түгәрәк даталары булганда, туган көннәре белән тәбриклибез. Ялгыз яшәүче ветеран укытучыларыбызга тимурчылык ярдәме оештырабыз.

Укыту-тәрбия процессында катнашучы һәркем:

-учреждениенең Уставын, эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә;

-эш сәгатьләрен җитештерүчән хезмәт өчен дөрес файдаланырга;

- янгын куркынычсызлыгын,хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә тиеш икәнлеген белеп эш йөртә.

Каникул вакыты эш көне булып тора..
"Кызыксындырып укыткан кеше генә белем бирә" дигән канатлы сүзләрне безнең укытучылар исләреннән чыгармыйлар. Укытучылар һәр 3 ел саен белем күтәрү курсларында яңалыклар белән танышып кайталар. Дәрес файдалы булсын өчен, көндәлек матбугаттан, өстәмә чыганаклардан, тарихи истәлекләрдән оста файдаланалар. Мөмкинлекләре булганда тәҗрибәләрен район укытучылары белән дә уртаклашалар. Бердәм Дәүләт имтиханнары биргәндә, вакытларын кызганмыйча, укучылар белән шөгыльләнәләр. Шуңа да укучыларыбыз әлеге имтиханнарны уңышлы гына бирәләр.

Педагогик хезмәткәрләр 5 елга бер тапкыр аттестацияләнәләр, педагогик эшчәнлектә яхшы нәтиҗәләргә ирешкән хезмәткәрләр аттестация вакытында өстенлекләрдән файдаланалар. Укытучыларның нәтиҗәле хезмәте игътибарсыз калмый, алар район Мәгариф бүлеге, район Админстрациясе, Мәгариф һәм фән минстрлыгы тарафыннан мактау грамоталары белән бүләкләнәләр.

Укучыларның җәйге ялы матур гына оештырылып килә. Безнең профсоюз члённарының балалары бу исемлеккә иң беренче кертелә.
Ашханәдә укытучылар да, укучылар да кайнар аш белән тәэмин ителгән. Пешекчеләребез эшләрен намус белән башкаралар.
Мәктәп чиста, пөхтә, җылы булсын өчен ярдәмче хезмәткәрләребез дә тырышып кына эшлиләр. Мәктәпнең чисталыгы укучылар сәламәтлеге өчен гаять әһәмиятле икәнлеген алар тирәнтен аңлыйлар.
Коллективта бер-береңә ярдәм итү, кайгы яки шатлык бүлешү, хезмәттәшеңнең хәленә керү кебек уңай сыйфатлар эшкә дәрт, күңелгә рәхәтлек бирә..
Гомумән, профсоюз оешмасындагы һәр кеше, үзенә йөкләнгән эшнең асылын аңлап, җаваплылык тоеп эшләргә тырыша.
Сүземне йомгаклап, Һәммәгезгә дә саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете, күңел тынычлыгы телим. Эшегездән тәм, тормышыгыздан ямь табып яшәргә язсын! Игътибарыгызга зур рәхмәт.